**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2024 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында гражданнарның үзара салымын кертү турында

25.03.2024 ел № 4

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләренә, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсенә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 15 мартындагы «2023 елның 17 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 2 санлы, 2023 елның 17 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 2/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү турында Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында»гы 6 санлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында узган гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «2023 елның 17 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында»гы 2 санлы, 2023 елның 17 ноябрендәге "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең Көрәш-Бүләк торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында»гы 2/1 санлы гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертеп, түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1)Көрәш-Бүләк торак пунктында су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, аларны чистарту, транспортлау һәм торак пунктта яшәүчеләргә су бирү (скважинаны бораулау, шамбо урнаштыру, төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2)Көрәш-Бүләк торак пунктында торак пункт территориясен төзекләндерү (санкцияләнмәгән чүплекне бетерү, килешү буенча эшләр өчен түләү);

3) Көрәш-Бүләк торак пунктында торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирлек эчендәге юлларны карап тоту, юлларны кардан чистарту, килешү буенча эшләр өчен түләү)».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында Бәйрәкәтамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында (http://jutaza.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (реер//pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Бәйрәкәтамак авыл җирлеге башлыгы ____________ З.М.Әһлиева
(имза